КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 14 июнь г.Казань № 425

2024/2025 елның ягу чорына Татарстан Республикасының ягулык-энергетика һәм торак-коммуналь комплекслары оешмаларын әзерләү мәсьәләләре турында

Татарстан Республикасында ягулык-энергетика һәм торак-коммуналь комплекслар оешмалары тарафыннан 2024/2025 елның ягу чорын тотрыклы уздыруга үз вакытында һәм нәтиҗәле әзерләнү максатларында һәм «Энергия саклау турында һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү хакында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 23 ноябрендәге ФЗ-261 номерлы һәм «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге ФЗ-190 номерлы федераль законнарны үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024/2025 елның ягу чорына әзерләнү буенча республика штабын оештырырга һәм аның составын (карарга теркәлә) расларга.

2. Республика башкарма хакимият органнарына һәм аларның ведомство буйсынуындагы оешмаларга түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына – гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

2024 елның 5 июленә кадәр:

узган ягу чорларында башкарыла торган эш күләмнәренең максимум дәрәҗәсеннән артып киткәндә килеп чыккан аварияләргә ясалган анализны исәпкә алып, 2024/2025 елның ягу чорында (алга таба – ягу чоры) Татарстан Республикасы оешмаларын һәм муниципаль берәмлекләрен эшләргә әзерләү (тормыш эшчәнлеген тәэмин итү системаларын диагностикалау, модернизацияләү, тузган һәм норматив эшләү срогы чыккан челтәрләрне һәм җиһазларны алыштыру, объектларны энергия ресурслары исәпкә алына торган приборлар белән җиһазлау чараларын үз эченә ала торган) чаралары планнарын эшләүне һәм раслауны;

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан расланган 2024 елга резерв ягулык хуҗалыклары һәм резерв ягулыгының норматив запаслары булу мәҗбүри булган Татарстан Республикасының газ кулланучылары – җылылык җитештерү чыганаклары исемлегенә кертелгән газ кулланучыларда – җылылык җитештерү чыганакларында резерв ягулыгының норматив запаслары булуны һәм резерв ягулык хуҗалыклары хәлен контрольдә тотуны тәэмин итүне;

ведомство буйсынуындагы объектларны гадәттән тыш хәлләр шартларында нормаль эшләсен өчен әзерләүне һәм электр энергиясенең резерв чыганаклары белән җиһазландыруны контрольдә тотуны тәэмин итүне;

2024 елның 1 августына кадәр җылылык, электр, ягулык һәм су белән тәэмин итү оешмаларының, җылылык энергиясе кулланучыларының, ремонт-төзелеш һәм транспорт оешмаларының, шулай ук җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеген исәпкә алып, җылылык белән тәэмин итү системаларында авария хәлләре салган зыяннарны бетерү буенча гамәлләр планын расларга;

2024 елның 15 сентябренә кадәр, тормыш эшчәнлеген тәэмин итү системаларын эксплуатацияләү өчен җаваплы оешмалар белән берлектә, тормыш эшчәнлеген тәэмин итү системаларында аварияләрне һәм бозуларны оператив бетерү өчен җиһазлар, материаллар һәм запас частьләр резервын булдыруны;

2024 елның 1 октябренә кадәр, вакыйгалар үсешенең иң начар вариантыннан (иң катлаулы авариядән) чыгып, җылылык белән тәэмин итү чыганакларында да, җылылык челтәрләрендә дә, шулай ук җылылык энергиясен кулланучылар объектларында да, шул исәптән күпфатирлы торак йортларга хезмәт күрсәтүче идарәче оешмаларны җәлеп итеп, авария нәтиҗәләрен бетерү гамәлләрен җентекләп эшләүне күздә тотып, авариягә каршы күнегүләр уздырырга;

җылылык белән тәэмин итү һәм кайнар су белән тәэмин итү системаларына план буенча ремонт ясауга бәйле кайнар су белән тәэмин итүне сүндерү буенча расланган графикларны үтәүгә юнәлдерелгән чаралар күрүне;

расланган бюджет йөкләмәләре лимитларын исәпкә алып, энергетика һәм коммуналь ресурсларны агымдагы куллану өчен үз вакытында һәм тулысынча түләүне тәэмин итүне;

бюджет йөкләмәләре лимитлары энергетика һәм коммуналь ресурсларны агымдагы куллану өчен түләргә җитәрмәгәндә, аларны яңадан карауны тәэмин итүне;

ягулык-энергетика ресурслары өчен түләүгә каралган бюджет акчасын максатчан файдалануны исәпкә алуны һәм контрольдә тотуны тәэмин итүне;

торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләренең (идарәче оешмалар, водоканаллар һәм җылылык челтәрләре предприятиеләренең) ягу чоры башланганга кадәр кулланылган ягулык-энергетика ресурслары өчен бурычларын каплау буенча чаралар күрүне;

ягу чорында эшләргә әзерләнүгә каралган акчаны максатчан файдалануны исәпкә алуны, үз вакытында, тулысынча түләүне контрольдә тотуны тәэмин итүне;

җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык кулланучы оешмаларның энергия җайланмаларына хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрне әзерләүне һәм аттестацияләүне (аларның белемнәрен тикшерүне) оештыруны;

җәйге чорда торак-коммуналь тармак хезмәткәрләрен авыл хуҗалыгы эшләренә җәлеп итмәүне;

энергетика һәм торак-коммуналь комплекс объектлары эшендә бозулар килеп чыккан очракта, (843) 231-14-10 телефон номеры, (843) 231-15-55 факс номеры буенча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, (843) 288-46-46, 288-46-57, 288-46-59 телефон номерлары буенча Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча дежур хезмәтенә мәгълүмат бирүне;

«Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясенең автоматлаштырылган мәгълүмат системасының торак-коммуналь хуҗалык объектларында аварияләрне һәм инцидентларны бетерүне мониторинглау һәм контрольдә тоту буенча ярдәмче системасына үз вакытында мәгълүмат кертүне тәэмин итүне.

3. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

федераль бюджет акчасы исәбеннән финанслана торган оешмалар җитәкчеләренә, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән берлектә, ягу чоры башланганга кадәр кулланылган ягулык-энергетика ресурслары өчен бурычларны каплау һәм агымдагы түләүләрне тәэмин итү буенча кирәкле чаралар күрүне;

электр, җылылык энергиясен тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтүче электр, җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару белән шөгыльләнүче предприятиеләргә өч – биш елга инвестиция планнарын төзегәндә аварияләргә һәм технологик сүндерүләргә анализ ясауны исәпкә алуны;

«Сетевая компания» акционерлык җәмгыятенә һәм Татарстан Республикасында электр энергиясен тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтүче оешмаларга 2024 елның 20 сентябренә кадәр законнар нигезендә электр белән тәэмин итү шартнамәләре һәм электр белән тәэмин итүне технологик һәм авария хәлендә броньлауны килештерү актлары нигезендә кулланучыларга электр энергиясен (куәтен) бирүне чикләү яисә вакытлыча туктату графикларын эшләүне һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, «Татарстан Республикасында ягулык-энергетика ресурсларын рациональ файдалануны һәм аларның сыйфатын тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештерүне;

«Татэнерго» акционерлык җәмгыятенә, «Сетевая компания» акционерлык җәмгыятенә, «ТГК-16» акционерлык җәмгыятенә, «Нижнекамская ТЭЦ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә, электр һәм җылылык энергиясен тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтүче башка оешмаларга, электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару режимында эшләүче оешмаларга, «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә һәм Татарстан Республикасында газ белән тәэмин итә торган башка оешмаларга:

җылылык электр станцияләрендә, электр һәм җылылык челтәрләрендә һәм газ белән тәэмин итү объектларында һәлакәттән торгызу эшләрен алып бару өчен материаллар һәм чаралар запасларын булдыруны;

2024 елның 1 октябренә кадәр Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Җылылык энергиясен, җылылык йөртүчене тапшырганда технологик югалтулар нормативларын, җылылык энергиясе җитештергәндә ягулыкның чагыштырма чыгымнары нормативларын, җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын (электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару режимында эшли торган җылылык энергиясе чыганакларыннан тыш), шул исәптән җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) дәүләт җайга салуы максатларында, технологик югалтулар нормативларын билгеләү тәртибе турында» 2012 елның 10 августындагы 377 номерлы боерыгы нигезендә резерв ягулыгы запасларын булдыруны;

2024 елның 5 ноябренә кадәр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасы субъектларының ягу сезонында эшләргә әзерлеген бәяләү һәм электр энергетикасы өлкәсендә электр энергетикасы субъектлары эшләре бозылу рискын мониторинглау тәртибе турында» 2017 елның 10 маендагы 543 номерлы карары нигезендә ягу чорында эшләргә әзерлек паспортын рәсмиләштерүне;

«Газпром межрегионгаз Казань» акционерлык җәмгыятенә, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ белән берлектә:

билгеләнгән, гарантияләнгән газ куллану күләме булуны исәпкә алып, ягу чорында ягулык-энергетика һәм торак-коммуналь комплекслар оешмаларын газ белән Татарстан Республикасында куллану өчен кирәкле күләмнәрдә ышанычлы тәэмин итү эшен башкаруны;

2024 елның 1 сентябренә кадәр 2024 елның IV кварталына һәм 2025 елның I кварталына суытканда кулланучыларны ягулыкның резерв төрләренә күчерү графигын һәм авария булганда газ-транспорт системасы эшенең технологик режимы бозылган очракта сатып алучыларны газ белән тәэмин итүне чикләү һәм аларны сүндерү чираты графигын эшләүне, аларны «Татарстан Республикасында Ягулык-энергетика ресурсларыннан рациональ файдалануны һәм аларның сыйфатын тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештерүне һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында раслауны;

предприятиеләргә – җылылык җитештерү чыганакларына – торак йортларны һәм социаль әһәмияттәге объектларны җылыта торган газ кулланучыларга (электр энергиясен җитештерүнең билгеләнгән куәте 25 мегаватт һәм аннан артыграк электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару режимында эшләүче җылылык энергиясе чыганакларыннан тыш) 2024 елның 15 июленә кадәр резерв ягулыгы запаслары нормативларын раслауга материалларны Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетына җибәрүне;

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан расланган 2024 елга резерв ягулык хуҗалыклары һәм резерв ягулыгының норматив запасы мәҗбүри булырга тиешле, торак йортларны һәм социаль әһәмияттәге объектларны җылыта торган Татарстан Республикасының газ кулланучылары – җылылык җитештерү чыганаклары исемлегенә кертелгән предприятиеләргә – табигый газ кулланычыларга 2024 елның 1 октябренә кадәр үз резерв ягулык хуҗалыкларын эшли торган хәлгә китерүне һәм аларны кирәкле резерв ягулыгы запасы белән тәэмин итүне;

«Татарстан Республикасында ягулык-энергетика ресурсларыннан рациональ файдалануны һәм аларның сыйфатын тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесенә 2024 елның 1 июленә кадәр 2025 елга резерв ягулык хуҗалыклары һәм резерв ягулыгының норматив запасы мәҗбүри булырга тиешле Татарстан Республикасының газ кулланучылары – җылылык җитештерү чыганаклары исемлеген әзерләүне һәм аны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында раслауны;

Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсенә 2024 елның 5 июленә кадәр Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Ягу чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы боерыгы белән расланган Ягу чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдә) нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең ягу чорына әзерлеген тикшерү программасын эшләүне һәм раслауны.

4. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына электр һәм җылылык энергиясен тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтүче, электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару белән шөгыльләнүче предприятиеләрнең ягу чорына әзерләнүен контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2025 елга, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ һәм «Газпром регионгаз Казань» АҖ белән берлектә, җирле бюджетлар акчасы исәбеннән финанслана торган оешмалар өчен ягулык-энергетика ресурсларын куллану лимитларын (натураль һәм кыйммәти чагылышта) законнар нигезендә, 2024 елның 1 сентябренә барлыкка килгән бурычларны исәпкә алып, әлеге оешмаларның нормаль яшәешен тәэмин итә торган дәрәҗәдә билгеләүне;

җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәләрендә җайга салына торган эшчәнлек башкару өчен файдаланыла торган күчемсез мөлкәт объектларына (биналар, төзелешләр, корылмалар, җир кишәрлекләре, хуҗасыз инженерлык челтәрләре) карата милек хокукын, биләү, файдалану һәм эш итү өчен башка законлы нигезләүне раслый, хокук билгели торган документларны (граждан-хокукый шартнамәләрне, концессия килешүләрен, юридик затны үзгәртеп оештырганда – тапшыру актларын) рәсмиләштерүне тизләтүне;

торак-коммуналь комплекс оешмалары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә авария-техник запас булдыруны контрольдә тотуны тәэмин итүне;

ягулык-энергетика һәм торак-коммуналь комплекслар объектларында гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракларда халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларын билгеләүне;

эксплуатацияләүгә тапшырыла торган яңа социаль өлкә объектларын һәм торак фонды объектларын әзерлек паспорты белән тәэмин итү максатларында, үз вакытында җылылык бирү өчен аларны ягу чорында файдалануга әзерләүне контрольдә тотуны тәэмин итүне;

идарәче компанияләрнең торак-коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен халыктан акча җыю буенча нәтиҗәле эшләвен оештыруны, шул исәптән

гражданнарның кулланылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләнмәгән бурычын каплауга юнәлдерелгән чаралар күрүне;

муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан предприятиеләрнең һәм оешмаларның электр, җылылык энергиясен һәм табигый газны агымдагы куллану өчен үз вакытында һәм тулысынча түләвен контрольдә тотуны тәэмин итүне;

гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча аларны алар өчен уңайлы вакытта кабул итүне оештыруны, гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча торак-коммуналь комплекс предприятиеләре җитәкчеләре белән ай саен киңәшмәләр практикасын дәвам итүне;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасы кысаларында газ белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системасын алмаштыруны тәэмин итүне;

йортта яшәүчеләр белән турыдан-туры идарә ителә торган күпфатирлы йортларның йорт эчендәге газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтүгә шартнамәләр төзүне тәэмин итүне;

киләсе ягу чорында катнаша торган предприятиеләрнең энергетика җиһазларын һәм куркыныч җитештерү объектларын эксплуатацияли торган, аттестацияләнгән белгечләрнең булуын контрольдә тотуны оештыруны;

2024 елның 15 июненә кадәр Кагыйдәләр нигезендә җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның ягу чорына әзерлеген бәяләү өчен комиссияләр төзүне, аларның составына Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсе вәкилен һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итүчеләрне кертүне;

2024 елның 5 июленә кадәр Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтнең Идел буе идарәсе белән җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның – җылылык энергиясен кулланучыларның ягулык чорына әзерлеген тикшерү графигын килештерүне;

2024 елның 1 сентябренә кадәр түбәндәгеләр буенча чаралар күрүне:

җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның резерв ягулык хуҗалыкларының эшли торган хәлдә булуын тәэмин итү һәм аларда кирәкле резерв ягулык запасын булдыру;

халыкның тормыш эшчәнлеген тәэмин итү системалары объектларының өзлексез эшләвен тәэмин итү өчен коммуналь хуҗалык оешмаларының мобиль дизель генераторларын эшли торган хәлгә китерү һәм аларны эшләтеп карау;

ягу чорына энергетика комплексы объектларын, сәнәгать һәм торак-коммуналь комплекс оешмаларын әзерләү чаралары планын үтәүне контрольдә тоту;

торак-коммуналь хуҗалык һәм социаль-мәдәни өлкә объектларының ягу чорына әзерлек паспортларын алу;

технологик хокук бозуларны бетерү, локальләштерү һәм җылылык, электр, ягулык һәм су белән тәэмин итүче оешмаларның, торак-коммуналь комплекс хезмәтләренең һәм башка оешмаларның гадәттән тыш хәлләрне һәм алар салган зыяннарны бетерү буенча күнегүләр үткәрү планын эшләү һәм раслау һәм ай саен аны үтәү барышы турында 2024/2025 елның ягу чорына әзерләнү буенча республика штабына мәгълүмат бирү;

2024 елның 1 ноябренә кадәр җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәре оешмалары тарафыннан Кагыйдәләр таләпләре нигезендә ягу чорына әзерлек паспортын алуны тәэмин итү;

2024 елның 15 ноябренә кадәр Кагыйдәләр таләпләре нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең ягу чорына әзерлек паспортын алу;

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь комплекс буенча дәүләт комитетының «Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында» 2003 елның 27 сентябрендәге 170 номерлы карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормалары (9 нчы кушымта) белән билгеләнгән таләпләр нигезендә әзерлек паспортларын рәсмиләштереп, ягу чорына торак-коммуналь хуҗалык һәм социаль өлкә объектларын әзерләүне төгәлләү һәм һәм аларны «Торак фонды мониторингы» системасында урнаштыру;

түбәндәгеләрне контрольдә тотуны тәэмин итүне:

ягу чорына халыкны һәм социаль өлкә объектларын җылылык белән тәэмин итүче объектларны әзерләүне;

халык күпфатирлы йортта турыдан-туры шартнамәләр буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә күчкән очракта, идарәче оешмаларның ресурслар белән тәэмин итүче оешмаларга бурычларын каплауны;

күпфатирлы йортлар хезмәт күрсәтү өчен яңа идарәче оешмага күчкәндә, ресурслар белән тәэмин итүче оешмаларга булган бурычларны (йөкләмәләрне) идарәче оешмаларга тапшыруны.

6. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына:

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе белән берлектә:

торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү исәпләүгә карата торак законнары таләпләрен үтәүне контрольдә тотуны көчәйтергә;

күпфатирлы йортларда капиталь ремонтны сыйфатлы итеп ясауны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән берлектә:

социаль өлкә һәм торак фонды объектларына җылылык бирә башлаган чорда «кайнар линия» телефоны буенча диспетчерлык хезмәте эшен оештырырга һәм җылылык бирә башлау датасы турында массакүләм мәгълүмат чараларында хәбәр итәргә;

коммуналь комплекс оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеген мониторинглау буенча, шул исәптән предприятиеләрнең кулланылган ягулык-энергетика ресурслары өчен бурычларын, бюджетка һәм бюджеттан тыш фондларга түләүләр буенча бурычларын каплауны тәэмин итүне контрольдә тоту буенча системалы эш оештырырга;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән берлектә, 2024 елның 1 октябренә кадәр:

үткән ягу чорлары йомгакларын исәпкә алып, ягу чорында Татарстан Республикасының ягулык-энергетика һәм торак-коммуналь комплекслары

оешмаларында мөмкин булган аварияләргә бәйле гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча оператив гамәлләр планына («Стужа») төзәтмәләр кертергә;

һәлакәттән торгызу формированиеләренең Татарстан Республикасы ягулык-энергетика һәм торак-коммуналь комплекслары оешмаларында гадәттән тыш хәлләрне бетерүгә әзерлеген тикшерүләрдә катнашырга.

7. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, халыкны һәм социаль-мәдәни билгеләнештәге учреждениеләрне коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итүче җылылык, су, электр һәм газ белән тәэмин итү предприятиеләре милекчесе үзгәргән очракта, читләштерү шартларында аларның билгеләнешендәге үзгәрешләрне чикләүне күздә тотарга.

8. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән берлектә:

идарәче компанияләр, торак милекчеләре ширкәтләре, торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан күпфатирлы йортларда һәм индивидуаль йортларда төтен һәм вентиляция каналларын тикшерүне тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

бүлмәләр милекчеләре төтен һәм вентиляция каналларын тикшерүдән баш тарткан очракта, тиешле газ приборларын сүндерү турында тәкъдимнәр белән «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә мәгълүмат җибәрергә;

түбәндәгеләрне контрольдә тотуны тәэмин итүне:

күпфатирлы йортларны ягу чорында эшләү өчен нәтиҗәле әзерләү, күпфатирлы йортларны индивидуаль җылытуга күчерү эшләрен вакытында тәмамлау чараларын үтәү барышын;

техник документация һәм норматив хокукый актлар нигезендә күпфатирлы йортларга үз вакытында капиталь ремонт ясауны;

2024 елның 1 июленнән 1 ноябренә кадәр, һәр айның өченче числосына кадәр «Торак фонды мониторингы» системасында бу карарның кушымтасында бирелгән форма буенча ягу чорында эшләргә әзерләнү барышы турында мәгълүмат урнаштыруны.

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023/2024 елның ягу чорына Татарстан Республи-касының ягулык-энергетика һәм торак-коммуналь комплекслары оешмаларын әзерләү бурычлары турында» 2023 ел, 7 июнь, 695 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

10. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигматуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 14 июнь, 425 нче
карары белән расланды

2024/2025 елгы ягу чорына әзерләнү буенча республика штабы
составы

| | |
|---|---|
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры, Республика штабы башлыгы |
| Фролов Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары, Республика штабы башлыгы урынбасары |

Республика штабы әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Вәлиуллов Рөстәм Фәйзрахман улы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары |
| Вахитов Рефат Рөстәм улы | «Газпром межрегионгаз Казань» акционерлык җәмгыяте генераль директорының хакимият органнары белән эшләү буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Гайфуллин Илгизәр Хәбир улы | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары – техник директоры (килешү буенча) |
| Галиев Эдуард Геннадьевич | «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Галләмов Айрат Азат улы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының торак-коммуналь хуҗалык идарәсе башлыгы |
| Галәвов Әсфан Галләм улы | «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Гаптраупов Рөстәм Әнәс улы | «Татарстан Республикасында ягулык-энергетика ресурсларын рациональ файдалануны һәм аларның сыйфатын тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы урынбасары |
| Гыйниятуллин Искәндәр Әнвәр улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Миннебаев Марат Фәйзрахман улы | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Миңнәхмәтов Җәүдәт Мидхәт улы | «Татарстан Республикасының Инженерлык челтәрләре баш идарәсе» дәүләт казна предприятиесе генераль директоры |
| Мөбарәкшин Азат Фәрид улы | Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Мөхәммәдиев Әмир Абдылнур улы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы |
| Поминов Андрей Иванович | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары |
| Салихов Мәҗит Хаҗип улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Сибгатуллин Илдар Нурзад улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсе башлыгы |
| Сөләйманов Рифнур Хәйдәр улы | «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыяте директоры (килешү буенча) |
| Суржко Николай Владимирович | Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы |

| | |
|---|---|
| Тыгин Александр Васильевич | Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы |
| Фәйзрахманов Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры |
| Фәрдиев Илшат Шәех улы | «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Фатыйхов Илдар Рәзин улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары |
| Хәбибуллина Лариса Васильевна | Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары |
| Хәйруллин Абрек Хафиз улы | «Татарстан Республикасының Коммуналь предприятиеләр берлеге» эш бирүчеләр төбәк тармак берләшмәсенең Директорлар советы рәисе (килешү буенча) |
| Хәкимҗанов Ленар Сәетҗан улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары |
| Хафизов Илнар Фәнил улы | «Татлизинг» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры |
| Хөсәенов Алмаз Әзһәр улы | Татарстан Республикасы спорт министры урынбасары |
| Чукин Артем Викторович | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары |
| Чучкалов Михаил Владимирович | «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары – баш инженеры (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 14 июнь, 425 нче
карарына кушымта

Форма

______________________________________________________________
(шәһәр (район) исеме)

2023/2024 елның ягу чорында эшләргә әзерләнү барышы турында
мәгълүматы

2024 елның «____» __________________на карата

| Күрсәткечләр | Юл саны | Үлчәү берәмлеге | ҮБГК буенча коды | Барлыгы | Әзерләнү буенча бирем | Хисап чорына кышкы шартларда эшләү өчен әзерләнде | Капиталь ремонт, реконструкция, алмаштыру эшләре башкарылды | Биремне үтәү %ы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Татарстан Республикасында Торак фонды, | 01 | мең берәмлек | 643 | | | | | |
| | 02 | мең кв.метр | 058 | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | | |
| дәүләт | 03 | мең берәмлек | 643 | | | | | |
| | 04 | мең кв.метр | 058 | | | | | |
| муниципаль | 05 | мең берәмлек | 643 | | | | | |
| | 06 | мең кв.метр | 058 | | | | | |
| хосусый | 07 | мең берәмлек | 643 | | | | | |
| | 08 | мең кв.метр | 058 | | | | | |
| Барлык милек рәвешләрендәге котельныйлар | 09 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Куәте, | 10 | Гкал | | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ* | 11 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Куәте | 12 | Гкал | | | | | | |

*ТКХ – торак-коммуналь хуҗалык.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Барлык милек рәвешләрендәге җылылык челтәрләре (ике көпшәле исәпләүдә), | 13 | км | 008 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 14 | км | 008 | | | | | |
| Милекнең барлык рәвешләрендә тузган җылылык челтәрләре (ике көпшәле исәпләүдә), | 15 | км | 008 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 16 | км | 008 | | | | | |
| Барлык милек рәвешләрендәге җылылык насос станцияләре, | 17 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 18 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Барлык формадагы үзәк җылылык пунктлары | 19 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 20 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Барлык милек рәвешләрендәге су алу җайланмалары, | 21 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 22 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Барлык милек рәвешләрендәге суүткәргеч насос станцияләре, | 23 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 24 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Барлык милек рәвешләрендәге суүткәргеч чистарту корылмалары | 25 | берәмлек | 642 | | | | | |
| үткәрү сәләте, | 26 | тәүлегенә мең куб метр | 599 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 27 | берәмлек | 642 | | | | | |
| үткәрү сәләте | 28 | тәүлегенә мең куб метр | 599 | | | | | |
| Барлык милек рәвешләрендәге суүткәргеч челтәрләре, | 29 | км | 008 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 30 | км | 008 | | | | | |
| Барлык милек рәвешләрендәге тузган суүткәргеч челтәрләре, | 31 | км | 008 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 32 | км | 008 | | | | | |
| Барлык милек рәвешләрендәге канализация насос станцияләре, | 33 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 34 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Барлык милек рәвешләрендәге канализациянең чистарту корылмалары | 35 | берәмлек | 642 | | | | | |
| үткәрү сәләте, | 36 | тәүлегенә мең куб метр | 599 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 37 | берәмлек | 642 | | | | | |
| үткәрү сәләте | 38 | тәүлегенә мең куб метр | 599 | | | | | |
| Барлык милек рәвешләрендәге канализация челтәрләре, | 39 | км | 008 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 40 | км | 008 | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Барлык милек рәвешләрендәге тузган канализация челтәрләре, | 41 | км | 008 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 42 | км | 008 | | | | | |
| Барлык милек рәвешләрендәге электр челтәрләре, | 43 | км | 008 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 44 | км | 008 | | | | | |
| Барлык милек рәвешләрендәге тузган электр челтәрләре, | 45 | км | 008 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 46 | км | 008 | | | | | |
| Барлык милек рәвешләрендәге трансформатор ярдәмче станцияләре, | 47 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 48 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Барлык милек рәвешләрендәге механикалаштырып җыештыру өчен махсус машиналар, | 49 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 50 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Барлык милек рәвешләрендәге урам-юл челтәре, | 51 | тәүлегенә мең куб метр | 058 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 52 | тәүлегенә мең куб метр | 058 | | | | | |
| Барлык милек рәвешләрендәге күпер корылмаларын (транспорт һәм җәяүлеләр күперләрен һәм юлүткәргечләрне), торбаларны әзерләү, | 53 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 54 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Барлык милек рәвешләрендәге транспорт һәм җәяүлеләр тоннельләрен әзерләү, | 55 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 56 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Барлык милек рәвешләрендәге гидротехник корылмалар әзерләү, | 57 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 58 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Газүткәргечләр | 59 | км | 008 | | | | | |
| Ягулык запасларын булдыру:<br>күмер | 60 | тонна | 168 | | | | | |
| башка каты ягулык | 61 | тонна | 168 | | | | | |
| сыек ягулык | 62 | тонна | 168 | | | | | |
| җир асты газсаклагычларында газ запаслары | 63 | мең кв.метр | 114 | | | | | |
| Традицион булмаган энергия чыганаклары, шул исәптән: | 64 | берәмлек | 642 | | | | | |
| су күтәрелә торган | 65 | кВт | 214 | | | | | |
| кояш нурлары | 66 | кВт | 214 | | | | | |
| җил | 67 | кВт | 214 | | | | | |
| термаль | 68 | кВт | 214 | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Муниципаль берәмлекләрнеңторак-коммуналь хуҗалыгын кышка әзерләү өчен түбәндәгеләргә бирелә торган Татарстан Республикасының финанс чаралары, шулардан: | 69 | млн.сум | 385 | | | | | |
| торак-коммуналь хуҗалык оешмалары һәм берлекләре өчен ягулык сатып алуга | 70 | млн.сум | 385 | | | | | |
| матди-техник ресурсларның авария запасларын булдыруга | 71 | млн.сум | 385 | | | | | |
| ТКХ объектларын төзүгә | 72 | млн.сум | 385 | | | | | |
| ТКХ объектларын капиталь ремонтлауга, модернизацияләүгә | 73 | млн.сум | 385 | | | | | |
| ТКХны кышка әзерләү өчен түбәндәгеләргә бирелә торган муниципаль берәмлекләрнең һәм ТКХ предприятиеләренең финанс чаралары, шулардан: | 74 | млн.сум | 385 | | | | | |
| ТКХ оешмалары һәм берәмлекләре өчен ягулык сатып алуга | 75 | млн.сум | 385 | | | | | |
| матди-техник ресурсларның авария запасларын булдыруга | 76 | млн.сум | 385 | | | | | |
| ТКХ объектларын төзүгә | 77 | млн.сум | 385 | | | | | |
| ТКХ объектларын капиталь ремонтлауга, модернизацияләүгә | 78 | млн.сум | 385 | | | | | |
| ТКХны җылыту чорына әзерләү өчен федераль бюджеттан өстәмә акча | 79 | млн.сум | 385 | | | | | |
| ТКХ оешмаларының элек кулланылган ягулык-энергетика ресурслары өчен бурычы, шул исәптән: | 80 | млн.сум | 385 | | | | | |
| күмер | 81 | млн.сум | 385 | | | | | |
| сыек ягулык | 82 | млн.сум | 385 | | | | | |
| газ | 83 | млн.сум | 385 | | | | | |
| җылылык энергиясе | 84 | млн.сум | 385 | | | | | |
| электр энергиясе | 85 | млн.сум | 385 | | | | | |

Торак-коммуналь хуҗалыкның төп фондларына
техник инвентарьлаштыру үткәрү
(1 июльгә карата елга бер тапкыр тутырыла)

| Т/с | Күрсәткеч | Агымдагы елның 1 июленә башкарылган, % |
|---|---|---|
| 1. | Торак фонды | |
| 2. | Котельныйлар | |
| 3. | Үзәк җылылык пунктлары | |
| 4. | Трансформатор ярдәмче станцияләре | |
| 5. | Суүткәргечнең чистарту корылмалары | |
| 6. | Канализациянең чистарту корылмалары | |
| 7. | Суүткәргеч насос станцияләре | |
| 8. | Канализация насос станцияләре | |
| 9. | Җылылык насос станцияләре | |
| 10. | Җылылык челтәрләре | |
| 11. | Суүткәргеч челтәрләре | |
| 12. | Канализация челтәрләре | |
| 13. | Электр челтәрләре | |

Оешма җитәкчесе

______________________ (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

______________________ (имза)

______________________ (форма төзү өчен җаваплы затның вазыйфа исеме)

______________________ (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

______________________ (имза)

______________________ (элемтәгә керү өчен телефон номеры)

20__ елның «___»______
(документны тутыру датасы)

______________________